ЯҢАЛЫКЛАР

Хәбиров Украинага каршы сугыштан Башкортстанга 4,5 меңләп хәрби кайтуын белдерде

9 ноябрь 2026



Иллюстратив фото

Азатлык Радиосы республикадан сугышта кимендә 11 283 кеше үлеме турында хәбәр таба алды.

Башкортстан башлыгы **Радий Хәбиров** Русия Украинага каршы алып барган сугыштан республикага 4,5 мең "чамасы" хәрби кайткан дип белдерде. Моны ул "зур булмаган сан" диде. Моңа Idel.Реалии басмасы игътибар иткән.

— Бу зур сан түгел, безнең 4,5 меңмең чамасы егет кайтты. Аларның 75% эшкә урнаштырылган. Аңлашыла, анда физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр дә

бар, — диде ул.

Башкортстан премьер-министры урынбасары **Руслан Хәбибов** сүзләренчә, республика оешмалары сугыштан кайтучыларны эшкә урнаштыру өчен 3 971 эш урынын бүлгән. Эш тапмаучыларның яртысы әлегә реабилитация үтә.



БУ ТЕМАГА:

Ике сәгать саен – бер үлем. Татарстан һәм Башкортстаннан сугышта үлүчеләр саны 20 меңнән артты

- Бу елның башында Хәбиров республикага сугыштан 3 меңнән артык хәрбинең кайтуын белдергән иде.
- 2025 елның декабрендә Башкортстанда сугыштан кайтучыларны эшкә урнаштыру өчен 1% квота кертелде. Республика Хезмәт министрлыгы исә бу канунны үтәмәүче ширкәтләрне штрафка тартырга тәкъдим итте.
- Русиянең Украинага каршы баскын сугышында Башкортстаннан күпме кеше катнашуы билгеле түгел, республика хакимияте бу санны ачмый. Шул ук вакытта, республика – сугышта үлүчеләр саны белән Русия төбәкләре арасында беренче урында.
- Азатлык Радиосы бүгенге көндә республикадан **11 283** кеше үлеме турында хәбәр таба алды. Үлүчеләр исемлеге ачык чыганаклардан туплана, чын сан күпкә зуррак булырга мөмкин.

🛑 **Русиядә Азатлык Радиосы сайты томаланды, нишләргә? Безнең кулланма.**
🌐 **Безнең Telegram каналына да кушылырга онытмагыз!**

This item is part of

яңалыклар | башкортстан | сугыш

Азатлык Радиосы © 2026 RFE/RL, Inc. | Бар хокуклар сакланган